Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

14.10.2022 ел

Менделеевск ш.

№625

Өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә
чакырылган затларның гаиләләренә социаль
ярдәмнең өстәмә чаралары турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы һәм хәрби хезмәткә чакырылган затларның гаиләләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Хәрби комиссариаты тарафыннан хәрби хезмәткәрнең мобилизация буенча хәрби хезмәт узуы чорында өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган хәрби хезмәткәрләр гаиләләренә түбәндәге өстәмә социаль ярдәм чараларын күрсәтергә:

1.1.Балаларны, яшь ярымга җиткәч, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына чираттан тыш җибәрергә.

1.2. Мәктәпкәчә белем бирүче мәгариф оешмаларында баланы карап торган һәм караган өчен алына торган түләүдән азат итәргә.

1.3.Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны бер мәртәбә түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итәргә;

1.4.Балаларга «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ буйсынуындагы учреждениеләрдә өстәмә белем бирү программалары буенча дәресләргә (түгәрәкләргә, секцияләргә һәм башка шундый дәресләргә) бушлай йөрүне тәэмин итәргә

1.5. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» МКУ, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МКУ буйсынуындагы учреждениеләрдә бушлай дәресләргә (түгәрәкләргә, секцияләргә һәм башка шундый дәресләргә) бару, шулай ук чаңгы, тимераяк һәм велосипедларны бушлай прокатка алу.

2. Менделеевск муниципаль районы финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктының 1.1-1.5 пунктчаларында күрсәтелгән чыгымнарны финанслауны 2022 елга Менделеевск муниципаль районы бюджетында каралган чаралар чикләрендә тәэмин итәргә.

3. Мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә:

3.1.ярдәм чараларын үз вакытында күрсәтү максатларында мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган хәрби хезмәткәрләрнең балалары санына даими мониторинг алып барырга;

3.2.мәктәпкәчә яшьтәге балаларны карауны оештырырга;

3.3.укучыларның тукллануын оештырырга;

3.4.Кирәк булганда өйдә белем алучыларга махсус медицина күрсәткечләре буенча туклану продуктлары җыелмасын бирүне оештырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырырга.

5. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча җитәкчесе урынбасары К.Г.Макаровка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы С.В.Метальников